СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**30 октябрь 2023 ел** **№9**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Үрнәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылында Югары Пошалым авылы, Сәләхова урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Югары Пошалым авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 16 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылында Югары Пошалым авылы, Сәләхова урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Югары Пошалым авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 16 ноябренә 11сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга:

1 нче этап: Сәләхова, Мичурин урамнарында яшәүчеләр;

2 нче этап: Ленин, Тукай, Урал урамнарында яшәүчеләр;

4. Халык җыенына чыгарылучы югарыдәгы мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган

балаларын) түләүдән азат итү һәм  җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмият-әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә  тотылуына ризамы:

1. Җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү.

2.  Агачларны санитар кисү һәм аларны чыгару.

3. Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ”                                        “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Югары Пошалым авылында  гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге  башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм  халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына югарыдагы адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Югары Пошалым авылы, Сәләхова урамы, 23 йорт.

7. Әлеге карар  басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы                                        В.Р.Габделхаков

СОВЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ